КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 396

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 май, 340 нчы; 2009 ел, 2 февраль, 56 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1156 нчы; 2011 ел, 4 ноябрь, 918 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 696 нчы; 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 52 нче; 2015 ел, 26 февраль, 116 нчы; 2016 ел, 19 май, 323 нче; 2016 ел, 3 сентябрь, 613 нче; 2018 ел, 14 апрель, 245 нче; 2019 ел, 7 май, 383 нче; 2019 ел, 12 сентябрь, 821 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хезмәткәрләренең иң чик санын түбәндәгечә билгеләргә:

аппарат буенча – вазыйфаи окладлары буенча 7 716,893 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 366 берәмлек;

территориаль органнар буенча – вазыйфаи окладлары буенча 11 288,705 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 696 берәмлек.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «, салым һәм валюта» сүзләрен «һәм салым» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта:

2.1.1 пунктчада «, салым һәм валюта» сүзләрен «һәм салым» сүзләренә алмаштырырга;

2.1.7 пунктчада «һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны анализлау» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

дәүләт финанслары белән идарә итү (01.02*);

финанс-бюджет өлкәсендә контрольдә тоту (01.02.01*);

Татарстан Республикасының эшләмәүче халкын мәҗбүри медицина иминләштерүен оештыру (04.02.08*).»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән башка) функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.02*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*).

---

*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.3 пунктта:

егерме беренче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

кырык бишенче һәм кырык алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет кредитын кире кайтару йөкләмәләре үтәлешен тәэмин итүдә бирелә торган җаваплылыкны үз өстенә алуның, банк гарантиясенең ышанычлылыгын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бәяләүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының дәүләт гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәлен анализлауны, тәэмин ителешнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне, шулай ук принципалның финанс хәлен мониторинглауны, Татарстан Республикасының дәүләт гарантиясен биргәннән соң бирелгән тәэмин ителешнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;»;

5.4 пунктның беренче абзацында «, салым һәм валюта» сүзләрен «һәм салым» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы структурасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 6 июль, 323 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 31 май, 396 нчы
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы структурасы**

